ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31.03.2021 д. Канаш №7

Канаш авыл җирлегендә 2021нче елның язгы чорында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында.

"Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2007нче елның 8нче ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында" 2009нчы елның 3нче августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Төбәк яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау хакында» 2013нче елның 31нче маендагы 372нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Канаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, тискәре табигать - климат шартлары барлыкка килгән чорда җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының конструктив элементларының сәләтен киметүне булдырмау максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021нче елның 1нче апреленнән 30нчы апреленә кадәр Канаш авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында 6 тоннадан артык массасы булган йөк белән яки йөксез транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүне кертергә (алга таба - язгы чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү)
- Канаш авылы Үзәк, Яшел, Тыныч урамнары буйлап;
- Түбән Күл авылы Яшьләр урамы буенча 18нче йорттан 33нче йортка кадәр, Боевая урамы буенча

2. Хәрәкәтне вакытлыча чикләү 3.12 "Транспорт чарасына туры килә торган массаны чикләү" юл билгеләрен урнаштыру юлы белән Россия Федерациясе Юл хәрәкәте кагыйдәләре белән каралган өстәмә мәгълүмат (табличкалар) 8.20.1 һәм 8.20.2 "Транспорт чаралары тибы" тамгалары белән гамәлгә ашырыла.

3. Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» муниципальара бүлегенең ЮХИДИ бүлегенә Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү режимын үтәүне контрольдә тотуны оештырырга тәкъдим итәргә.

4. 2021 елның 1 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының "Татарстан Республикасының рәсми порталы" дәүләт мәгълүмат системасы составына керүче рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында вакытлыча чикләүләр кертү турында мәгълүмат урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков